**Зеленодольск муниципаль район Советы**

**КАРАР**

**4 март 2019 ел** **№ 369**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләрен раслау турында»гы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2012 елның 15 март 135нче карарына үзгәрешләр кертү турында (Зеленодол муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендәге 315нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

Зеленодольск муниципаль районы башлыгы урынбасары Кадникова Э.Р. мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы (№25-ФЗ 02.03.2007 ел) Федераль законга яраклы рәвештә, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә, Зеленодольск муниципаль район Советы түбәндәге карарны кабул итте:

1.Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибе турындагы, Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган 2012 елның 15 мартында 135нче «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләрен раслау турында»гы (Зеленодольск муниципаль районы Советы ның 2018 елның 9 июлендә 315нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Кагыйдәгә (алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Кагыйдәнең 4нче пункының 5нче өлешендә «һәм зурлар» сүзләрен «,зурлар һәм алып баручылар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2)10нчы пунктны яңа редакциядә язарга:

«10. Бәйгедә катнашырга теләүчеләр, конкурс комиссиясенә түбәндәге документлар беркетелгән гариза тапшыралар:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең боерыгы (№667-р, 26.05.2005 ел) белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

2) паспорт;

3) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагы булмаганда, хезмәт кенәгәсе;

4) 2елеем турында документ;

5) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагы булмаганда, пенсияне мәҗбүри иминиятләштерү таныклыгы;

6) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органына учетка кую турында таныклык;

7) запастагы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен – хәрби учет документы;

8) муниципаль хезмәткә керешүгә киртә булмаслык авыруларның юклыгы турында медицина оешмасы биргән белешмә;

9) «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр һәм Россия Федерациясе Президенты актларының кайберләренә үзгәрешләр кертү турындагы белешмә формаларын раслау турында»гы (23.06.2014 ел, №460) Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган форма буенча тутырылган конкурс уздырылган елдан алдагы календарь ел өчен керемнәр турында, гражданинның милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре һәм шулай ук, хатынының (иренең) конкурс уздырылган елдан алдагы календарь ел өчен керемнәр, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре, гражданинның балигъ булмаган балалары турында мәгълүмат;

10) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» (02.03.2007 ел, №25-ФЗ) Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган мәгълүмат;

11)Федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күрсәтелгән башка документлар;

1.3. Зеленодол муниципаль районы Советының 2012 елның 15 март 135нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләренә кушымтаны үз көчен югалткан дип исәпләргә.

2.Шушы карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталы составындагы Зеленодол муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодол муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В.Тыгин**